| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

17.06.2025 Балык Бистәсе штп. №145пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 17 августындагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы 234пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 17 августындагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы 234пи номерлы карарына (2025 елның 5 февралендәге 31пи номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 4 абзацындагы «13 990» санын «15 389» санына алмаштырырга;

1.2. 3 пунктның 3 пунктчасындагы «37» санын «52» санына алмаштырырга;

1.3. 8 пунктның 4 пунктчасындагы «37» санын «52» санына алмаштырырга;

1.4. «Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе аерым оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре» исемле 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

1.5. «Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе аерым оешмаларының структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре» исемле 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2025 елның 17 июнендәге
145 пи номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе аерым оешмаларының структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре

| N п/п | Вазыйфаның аталышы (исеме) | Вазыйфаи айлык хезмәт хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| | | V төркем |
| 1. | Мөстәкыйль идарә ( бүлек) җитәкчесе | 20 622 |
| 2. | Мөстәкыйль идарә ( бүлек) җитәкчесе урынбасары | 20 006 |
| 3. | Бүлек башлыгы | 19 237 |
| 4. | Бүлек башлыгы урынбасары | 18 006 |
| 5. | Баш белгеч | 16 928 |
| 6. | Әйдәүче белгеч | 16 159 |
| 7. | 1 категория белгеч | 15 389 |
| 8. | 2 категория белгеч | 15 389 |
| 9. | Белгеч | 15 389 |

Искәрмә:

V төркем - Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Лениногорск, Нурлат, Чистай һәм I - IV төркемнәргә кертелмәгән Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2025 елның 17 июнендәге
145 пи номерлы карарына
кушымта №2

Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсе аерым оешмаларының структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре

| Вазыйфаларның аталышы (исеме) | Вазыйфаи айлык хезмәт хакы, сумнарда |
|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинкада язу, күчерү-күбәйтү бюросы мөдирләре, инспектор, статистик, хуҗалык, склад мөдирләре; кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографистка, секретарь-стенографистка, машинистка, экспедитор, секретарь-машинистка, җитәкче сәркатибе | 15 389 |